
# Габдулла Тукай шигырьләре



http://aida.ucoz.ru

# Кызыклы Шәкерт

**Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор;**
**Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!**
**— Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;**
**Мин туганга тик ике айлап булыр йә өч кенә.**
**Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;**
**Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.**
**— Ах, җүләр маэмай! тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул:**
**Картаеп каткач буыннар — эш белү уңгайсыз ул!**



http://aida.ucoz.ru

# БАЛА БЕЛӘН КҮБӘЛӘК

*Бала:*

Әйт әле, Күбәләк,

Сөйләшик бергәләп:

Бу кадәр күп очып

Армыйсың син ничек?

Ничек соң тормышың?

Ничек көн күрмешең?

Сөйләп бирче тезеп,

Табаламсың ризык?



*Күбәләк:*

Мин торам кырларда,

Болында, урманда;

Уйныймын, очамын

Якты көн булганда.

Иркәли һәм сөя

Кояшның яктысы;

Аш буладыр миңа

http://aida.ucoz.ru

# Бишек җыры

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Йокла, угълым, йом күзен,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем;
Сина теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!




http://aida.ucoz.ru

# Безнең гаилә

**Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи –**
**Безнең өйдә без җидәү: безнең песи — җиденчесе.**

**Бергә ашый, чәй эчә, безнеңлә бергә йоклый ул,**
**Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.**



http://aida.ucoz.ru

# Гали белән Кәҗә

Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.


Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый — сакалын селкетә.



http://aida.ucoz.ru

# Кошчык


Кичә мин читлек ачтым, андагы кошчыкны коткардым,
Күңелсез тоткынымны киң яшел урманга кайтардым.
Аңар бирдем азатлык мин, үземдә шул вакыт күрдем:
Тынычлап калды никтер һәм тәмам иркенләде күңлем.
Күзем берлән озаттым: кошчыгым урман таба очты,
Югалды күк йөзендә тиз вакытта, бер дә юк төсле.
Очып киткәндә ул шундый матурлап сайрады моңлы:
Миңа, санки, азат иткән өчен изге дога кылды.



http://aida.ucoz.ru

# Көз

Күрәмсез, дустларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.
    Китә башлады бездән инде кошлар;
    Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.
Мисале зәгъфыран саргайды урман,
Игенчеләр игеннәрне дә урган.
    Такыр калды татар башы кеби кыр;
    Азык эзли — оча тургай да пыр-пыр.
Чыгып баш калкыта сахрада уҗым,
Яшел хәтфә шикелле итә җем-җем.



http://aida.ucoz.ru